КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 9 гыйнвар г.Казань № б-2

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 7 август, б-1504 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 сентябрь, б-2088 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Программа продуктын эшләүнең һәм аның эшләвен тәэмин итүнең бик күп көч куюны таләп итүне һәм аның кыйммәтен бәяләү буенча методик тәкъдимнамәләргә 2 нче кушымтада:

5 пунктның 2 графасындагы дүртенче абзацында «җылылык, кайнар су белән тәэмин итү, Мкалл» сүзләрен «җылылык, кайнар су белән тәэмин итү, Мкал» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның 4 графасында «2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 30 июненә кадәр коммуналь хезмәтләргә тарифлар» сүзләрен «программа продуктын эшләп чыгару һәм (яисә) модернизацияләү кыйммәтен исәпләгәндә, аена бер хезмәткәргә коммуналь хезмәтләр куллану кыйммәте күрсәткеченә карата Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан агымдагы һәм киләчәк чорларга раслана торган индекс-дефляторлар кулланыла» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 4 графасына «программа продуктын эшләп чыгару һәм (яисә) модернизацияләү кыйммәтен исәпләгәндә, аена бер хезмәткәргә матди-техник тәэмин итү кыйммәте күрсәткеченә карата Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан агымдагы һәм киләчәк чорларга раслана торган индекс-дефляторлар кулланыла» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин